# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман  Морквашы торак пунктында
2025 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

2024 елның 02 декабреннән №11

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең Урман  Морквашы торак пунктында гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең  Урман Морквашы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән  2000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Урман Морквашы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Яр Буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ________________И.Х. Гаязов